КАЗАКЪСТАН ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ БАШКОРТЛАРЫ КОНГРЕССЫ

*Единство в многообразии*

# ФИКЕР

**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир**

**№6 (119) 2018 ел**

**Газета «Фикер» выходила в 1905-1907 гг. при участии Габдуллы Тукая. С 1993 г. выходит в г. Алматы: с 2000 г. под названием «Фикер-Өмет», с 2013 г.«Фикер».**

---




**21 июль көнне Казанда Бөтендөнья татар конгрессының VII чираттан тыш съезды үткәрелде. Бу чарада Казакъстан татарларының делегациясе дә катнашты.**

**Казакъстан татарлары һәм башкортлары конгрессының рәисе Тәүфикъ Әкрам улы Кәримов Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең урынбасары итеп сайланды.**



## РИНАТ ЗАКИРОВКА 70 ЯШЬ

Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесе, «Казан» милли мәдәни үзәгенең директоры, тарих фәннәре докторы Ринат Зиннур улы Закиров 1948 елның 1 августында Чистай районының Нарат-Елга авылында дөньяга килә.

1972 елда Ринат Закиров Казан химико-технологик институтын тәмамлап, «инженер-химик» белгечлегенә ия була, үзенең хезмәт юлын шушы ук институтта инженер сыйфатында башлап җибәрә. Тиздән аны яшьләр белән эш алып бару өлкәсенә күчерәләр: ул комсомолның Татар өлкә комитетында пропаганда бүлегенең инструкторы булып эшли, соңрак бүлек мөдире урынбасары, пропаганда һәм мәдәни-масса бүлегенең мөдире була.

1980 -1988 елларда КПСС ның Татар өлкә комитетында мәдәният бүлеге инструкторы, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдиренең урынбасары булып эшли. 1991 елдан башлап, Ринат Закиров- «Казан» милли мәдәни үзәгенең директоры, 1996 елдан- Казан шәһәре мәдәният идарәсе начальнигының урынбасары. Шушы елларда диссертация хәзерләп, педагогика фәннәре кандидаты, дәрәҗәсен алган. Аның гыйлемгә, фәнгә омтылуы соңрак тарих фәннәре докторы дәрәҗәсенә күтәргән.

2002 елда Ринат Зиннур улы Бөтендөнья татар конгрессының рәисе итеп сайлана; 2017 елдан башлап, ул-Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесе.

Р.З.Закиров җитәкчелегендә БТК ның һәм аның Башкарма комитетының эшчәнлеге киңәйде, башка төрле яңа формаларга баеды. Татар хатын-кызлар форумы, татар яшьләре форумы һәм тагын башка шундый чаралар уздырыла башлады. Татар хатын-кызларының оешмасы булдырылды, татар эшкуарларының ассоциациясе корылды. Дөнья буйлап таралган татар төркемнәре белән БТК тыгыз элемтәләр урнаштырып, аларны да уртак эшчәнлеккә җәлеп итте. Дәүләт органнары, мәдәни оешмалар, милли-мәдәни үзәкләр, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр белән хезмәттәшлек яңа югары баскычка күтәрелде. Шушы елларда Федераль сабантуйлар, Еропа илләре сабантуе оештырыла башлады. Мондый чараларның күбесе Ринат

Закировның турыдан-туры катнашында узды. БТК ның шундый күптөрле эшчәнлеге татарларның үзаңын үстерүгә, аларның берләшүенә көчле этәргеч булды. БТК һәм аның рәисе бөтен татар дөньясында танылa торган объект булдылар, Ринат Зиннуров нигезле рәвештә югары абруй яулап алды.

Бүгенге катлаулы шартларда татар халкын берләштерү, һәрбер татар кешесендә бердәм һәм үзенчәлекле милләтнең вәкилемен дигән хисне, аның милли үзаңын ныгыту юнәлешләрендә алып барылган эшчәнлек Ринат Закировның катнашуында дәвам итте, шушы эшчәнлеккә ул зур көч, күп вакыт һәм бетмәс-төкәнмәс энергия сарыф итте. Татар милли-мәдәни хәрәкәтенең шушы чорда үсешендә Р.З. Закировның, һичшиксез, зур өлеше бар.

Закиров Ринат Зиннуровичның иҗтимагый эшчәнлеге киң өлкәне үз эченә ала. Ул - Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты, депутат рәтендә- Мәгариф, мәдәният, гыйлем һәм милли мәсьәләләр комитетының әгъзасы, Татарстан Республикасы Президенты алдындагы, ватандашлар Координацион Советының әгъзасы, Мәдәният Министрлыгының коллегиясе әгъзасы.

Ринат Закировның хезмәте югары бәһага лаек булган: ул- Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе, медальләр белән бүләкләнгән.

=======================

## КОТЛАУ

**Хөрмәтле Ринат Зиннур улы!**

Казакъстанда яшәүче татарлар исеменнән Сезне олы юбилеегыз белән ихлас күңелдән котларга рөхсәт итегез!

Без, Казакъстандагы татарлар, Сезнең җылы карашыгызны, кешеләргә ярдәм итәргә әзер икәнлегегезне һәрвакыт тоеп тордык, милли-мәдәни тоеп тордык, милли-мәдәни хәрәкәтебездә Сезгә таяндык. Иҗтимагый хезмәтебездә кыенчылыклар туганда, Сезнең акыллы киңәшләрегез байтак проблемаларны чишәргә мөмкинчелек бирде. Казакъстандагы татарлар Ринат Закировны чын күңелдән үзебезнең татарыбыз дип кабул итте.

Сезнең шушы хезмәтегез, һәркем белән дә дөрес һәм ихтирамлы аралашу оештыра белүегез- болар барысы да Сезне бөтен дөньяга таралган милләттәшләребез алдында чын ихтирамга лаеклы шәхес итеп танытты. Бөтендөнья татар Конгрессының какшамас абруенда, һичшиксез, Сезнең фидакарь хезмәтегезнең бәхәссез олы урыны бар.

**Кадерле Ринат Зиннур улы!**

70 яшьлек юбилеегыз көнендә без Сезгә барлык изге теләкләребезне юллыйбыз. Ходай Тәгалә бөтен теләкләрегезне, хыялларыгызны гамәлгә ашырырга юл ачсын!

Киләчәктә дә бергә-бергә, кулга кул тотынышып туган халкыбызның мәнфәгатьләре өчен тагын да озак еллар дәвамында хезмәт итәргә насыйп булсын!

***Кәримов Т.Ә.*** *– БТК Милли Шурасы рәисенең урынбасары, Казакъстан татарлары һәм башкортлары конгрессы идарәсенең рәисе;*

***Хәйруллин Г.Т.*** *- Казакъстан Республикасы мәгарифенең мактаулы хезмәткәре,Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, педагогика фәннәре докторы, профессор, академик;*

***Муллашев К.В.*** *- Казакъстан Республикасының дәүләт бүләге иясе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, профессор;*

***Ахунҗанов Г.Г.*** *- Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, атказанган сәнгать хезмәткәре.*

***1 август 2018 ел,***
***Астана ш., Казакъстан Республикасы***

## ҮЗГӘРӘ ТОРГАН ДӨНЬЯДА ТАТАРЛАР

Тарих фәннәре докторы Р.З. Закиров татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында фәнни эзләнешләр алып барган галимнәрнең берсе. Шушы проблемага төпле анализ ясап, ул «Татары в меняющемся мире. Очерки этнополитической истории в XX- начале XXI вв.» исемендәге китабын бастырып чыгарды.

Милли проблемаларга бүгенге көндә җитди мөнәсәбәт булырга тиешлеген автор менә ничек нигезли: «XX гасырның азагында дөньяда мөһим үзгәрешләр булды, менә шулар идеология өлкәсендә иң беренче нәүбәттә милләтләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр проблемасына кагыла... Хәзерге җәмгыять глобализация шартларында яши, ... халыкларга һичшиксез югалу һәм аларның этник үзенчәлекләренә унификацияләнү яный... Бүген галимнәр барган саен күбрәк шул фикергә борыла ки, милләт- реаль берлек икән, аның үзенә хас сыйфатлары бар, аның мәнфәгатьләре һәм кыйммәтлекләре башка мәнфәгать һәм кыйммәтлекләрдән өстен тора, милләт үзе мөстәкыйльлеккә, билгеле бер сәяси суверенитетка омтыла». Димәк, милләтләр проблемасын хәзерге вакытта иң мөһим, әһәмиятле бер проблема, дип танырга кирәк.

Милли проблемаларны автор нигезле рәвештә үзенең туган халкы - татарлар мисалында ачып бирә. Беренче нәүбәттә, монда «татар проблемасы» дигән төшенчә турында сүз бара. Бу мәсьәләнең тирән тарихи тамырлары барлыгын, 1552 елдагы фаҗигадан соң, яки татарларның үз дәүләтчелеген югалтканнан соң хасил булуын күрсәтә автор. Татар проблемасының төп нигезен Р.З.Закиров: «татар халкының үзенең үзенчәлекле мәдәниятен, туган телен, милли белем бирү системасын, динен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү» хокукларына бәйләгән.

Татар халкының Рәсәй империясендәге язмышына килгәндә, автор бу халыкка һәр төрле кыен шартларда үзенең хокуклары өчен өзлексез көрәш алып барырга туры килгәнен ассызыклый. Д.М. Исхаковның материалларына таянып, Волга буе мөселманнарының саны XVII гасырга кадәр өч мәртәбә кимегәнен искә төшерә автор. Әлбәттә, бу күренеш- бөек рус шовинизмының, руслаштыру сәясәтенең бәхәссез дәлиле булып тора. Гадәттәге Мәскәү пропагандасындасы: «рус булмаган халыкларга бөек рус халкы алдынгы мәдәният һәм белем алып килде, кыргыйлыктан коткарды», дип раслый. Ә менә монда китерелгән һәм шуңа охшаган материаллар Мәскәү тезисының тарихи чынбарлыктан бик ерак торуын бәхәссез фактка әйләндерәләр.

Казан яулап алынгач, Мәскәү дәүләте көчләп христианлаштыру сәясәтен һәртөрле ысуллар белән (шул хисаптан, ерткычлык, алдау, сатып алу, һ.б.ш. ысуллар белән) киңәйтеп җибәрә. Ислам диненә каршы бу дөньяда тарихта да күренмәгән вәхши сугыш башлана. Мәскәүнең мессианлык идеологиясе нигезендә татар халкының (һәм яулап алынган бүтән халыкларның да) зыялыларын юкка чыгару, сәнәгатен, мәдәниятен җимерү һ.б.ш. күренешләр колониаль хакимиятнең аерылмас билгесенә әверелә. Шушы регионның төп халыклары бөтен хокукларыннан мәхрүм ителә, Мәскәү колониаль хакимиятенең бер генә сүзенә каршы чыгу да кичерелмәслек җинаять исәпләнә. Шушы халәттә яулап алынган халыклар алдына үзен-үзе ничек тә саклап калу мәсьәләсе килеп баса.

Татар халкының Рәсәй империясе составындагы тормышы авыр да, фаҗигале дә төс ала. Халыкның Мәскәү хакимиятенә каршы чыгулары канлы җәзалаулар белән тәмамлана. Шушы чор татар халкы тарихының иң кара периоды, дияргә була. Шулай да, шушы периодның эчендә дә теге яки бу күренешләр белән аерылып торган вакытларны аерырга мөмкин. Мисал өчен, Р.С.Хакимов түбәндәге периодизацияне тәкъдим итә.

1 этап- 1552 елдан башлап XVIII гасырның 80 нче елларына кадәр. Бу- иң озын һәм фаҗигале этап, татарларның

чиксез авыр сәяси һәм социаль-икътисади шартларда исән калу өчен тырышып-тырмашу чоры.

2 этап- XIX гасырның соңгы чирегенә кадәр дәвам итә. Монда татар халкы шул чордагы Рәсәй шартларына күнегергә хәрәкәтләнә.

3 этап- XX гасырның башына кадәр, Октябрь инкыйлабына хәтле дәвам итә. Татар җәмгыятенең һәртөрле өлкәләрендә үзгәрешләр булган вакыт; аны татар ренессансы, яңарышы этабы дияргә була.

4 этап- совет чоры, ягъни XX гасырның 80-90 нчы елларына кадәрге вакыт. Бу чорда татар халкы күренерлек уңышларга иреште һәм шуның белән бергә билгеле югалтуларга да дучар булды.

5 этап- милләтнең яңадан торгызылуы. Татарстанның дәүләт суверенитеты хакындагы Декларацияне, татар җәмгыятендәге билгеле үзгәрешләрне, процессларны күрсәтергә була монда.

1552 елдан соңгы чорда кайсы гына периодны карама, татар халкы алдында аерым, үзенчәлекле, мөстәкыйль милләт рәтендә сакланып калу мәсьәләсе торган. Шундый авыр шартларда да, күпме югалтулар кичергәндә дә татар халкының милләт рәтендә саклануы- бу, беренче нәүбәттә, татар милли үзаңы дәрәҗәсенең чагылышы, дип бәяләргә кирәк.

Шушы тарихның һәрбер чорын аерым-аерым карап, Р.З.Закиров сыйфатламалар биреп чыга. Монда Рәсәй хакимиятенең татарларны тыю, кысу, руслаштыру, дискриминацияләү, христианлаштыру сәясәте алып барылуына игътибар ителә. Совет чорына килгәндә, автор татарларның 1917-18 еллардагы сәяси җитешкәнлеген, милли дәүләтне торгызуга куәтле омтылышын ассызыклап күрсәтә. Эчке Рәсәй һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе, Идел-Урал штаты, Татар-Башкорт Совет Республикасы проекты һәм башка да гамәлгә ашмый калган мөмкинчелекләргә туктала.

Р.З. Закиров милли хәрәкәт һәм хәзерге заманда милләтләрнең формалашу мәсьәләләренә дә анализ ясый, шул кысаларда татар-башкорт мөнәсәбәтләрен ачыклый. Ике тугандаш халык арасындагы ясалма корылган каршылыкларның тамырлары 1918-1919 елларда ятканын күрсәтә. Уфа губернасының татарлар яшәгән районнарын көчләп Башкортостанга кушу «киләчәктәге һәм бүгенге көнгәчә сузылган тарткалашның нигезен салды»,- дип күрсәтә автор. Шуны да өстәргә кирәк, башкортлар яшәгән байтак районнар шул ук юл белән Чиләбе, Пермь һәм башка өлкәләрдә бүлеп калдырылды. Мондый хәлдә аларның тиз арада ассимиляцияләнәчәге көн кебек ачык иде.

Татар милли мәгърифәте проблемасы китапта билгеле бер урын алып тора. Идел буе Булгариясе һәм Казан ханлыгында шул чорның алдынгы мөселман мәдәнияте таралган, мәктәпләр һәм мәдрәсәләр эшләп торган. Әмма 1552 елгы фаҗигадан соң «мәдәни, дини, гыйлем үзәкләренең һәм институтларының бик күп өлеше юкка чыгарыла. Татарлар шәһәрләрдән куыла, шулай итеп, халык югары дәрәҗәле шәһәр мәдәниятен югалта. Шул мәдәниәят белән бәйле булган гыйлем системасы таркалуга дучар ителә» (Р.З.Закиров).

Шуның белән бергә оккупантларның кулы җитмәстәй урыннарда татар халкы мәктәпләрне, мәдрәсәләрне, китаплар күчереп язу осталыгын ничек тә сакларга тырышкан. Бу эшләрне хакимият түгел, халык үзе генә тәэмин иткән. Шулай итеп, татар халкының гыйлемгә омтылуы белән үзенчәлекле милли мәгърифәт торгызыла. Тик 1917 елгы инкыйлабтан соң гына татар мәктәбе тулысынча дәүләт тәэминатына күчерелә һәм хакимият программалары буенча эшли башлый.

Гомуми татар тарихын һәм, аерым алганда, татар мәгърифәте тарихын ислам дине тәэсиреннән аерып карап булмый. Идел буе регионына ислам диненең үтеп керүе мондагы халыкның көнчыгыш илләре белән күпьеллык сәүдә-икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре урнашкан булуына, шулай ук гарәп миссионерлары тырышлыгына бәйле. Татар милли мәгърифәт системасы күпме гасырлар дәвамында дин әһелләре- муллалар

кулында булган. Алар руслаштыру, христианланштыру сәясәтенә каршы көрәштә актив катнашкан. Шулай итеп, татар халкының үзенчәлекле аерым милләт булып саклануында ислам дине әһелләре аеруча зур урын алып тора.

1920 елда Татар Автономияле Совет Республикасы төзелә. Шушы мәсьәләгә кагылып, Р.З.Закиров татарларның тулы хокуклы союз республикасы корудан яңадан мәхрүм ителүен күрсәтә. Моннан башка да, «Республиканың чикләре шулай итеп билгеләнде ки, өч миллион диярлек татарлар милли-дәүләт корылмасыннан читтә калды, -дип күрсәтә ул.- Бу хәл бүгенге көнгә кадәр дәвам итә, татар халкының белем бирү, мәдәният, туган телен саклау һәм үстерү проблемаларын чишүдә зур кыенчылыклар тудыра». Шуны да кушып әйтик, бүленеп калган татарларның таркалуына, ассимиляцияләнүенә юл ача.

Автономияле Республика- «икенче сорттагы» корылма инде ул. Аның үз Фәннәр академиясе дә, энциклопедик басмалары да, кинематографы да булырга тиеш түгел. Шундый ук булырга рөхсәт ителмәгән объектларны һ.б.ш. санап китсәң, бу халыкны махсус рәвештә башка милләттәрдән артта калдырырга исәпләгәннәр ләбаса, дигән уй туа. Бу гына да түгел, халыкның үзаңын түбәнләтер, аның тарихын кара төскә буяр өчен хакимият һәрвакыт мөмкинчелек тә, кирәкле чараларын да таба белгән.

Мисал өчен, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында бәян ителгән «О состоянии и мерах улучшения массово-политической работы и идеологической работы в Татарской партийной организации» исемендәге карарын гына алыйк. Датасына караганда, СССР ның уттай сугышта янган чоры, нихәтле корбаннар китерү хисабына бөек Җиңү көненә җиткәнче дә бер елга якын вакыт үтәчәк әле. Шундый шартларда сәяси һәм идеологик эшне яхшырту мәсьәләсе алга баскан икән, бу халыкның сугыш чорында гаепләре бардыр, дип фараз итәргә кала. Әмма бу канлы сугыш нәтиҗәләренә карасаң, татарлар алгы сафларда булган бит! Сугыш чорында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар исәбендә татарлар бөтен СССР халыклары арасында дүртенче урынны билән тора. Болай булгач, бәлки, шундый авыр чорда, бөтен көч һәм кайгырту фронтка юнәлтелгәндә, берәр һич кичектерелмәслек проблема туды микән?

Юк шул! Баксаң, татарлар үз тарихын карый башлаганнар ләбаса, халык дастаны «Идегей» дә табылган. Гәрчә дастанда руслар белән сугышулар турында сүз бармаса да, моны ашыгыч рәвештә тыярга кирәк булып чыккан. Бу мәсьәлә сугышта җиңеп чыгуга, халык хуҗалыгын торгызу мәсьәләсенә караганда да мөһимрәк, кичектермәслек булган хакимият өчен. «Сугышның кызган чагында совет хакимиятендә татарларның үз тарихына «дөрес булмаган мөнәсәбәте»ннән дә мөһимрәк проблема булмаган» (Р.З.Закиров).

Бүген дә Рәсәй хакимиятендә «татар проблемасына» караш нигездә үзгәрмәгән кебек, тик аның формалары һәм эчтәлеге генә башка булырга мөмкин. Моңа мисал итеп Р.З. Закиров 2001 елда кертелгән Рәсәй гражданины паспортларында «милләте» дигән графаның юкка чыгуын атап китә. Кешенең милләте хакындагы информация җанисәбен алганда да искә алынмый. Соңрак кешенең туган телен дә искә алмый башлыйлар. Милләтләр мәсьәләсе буенча эшләп килгән махсус министрлык ябыла. Шулай итеп, рус булмаган милләтләрнең үсеше, аларның туган телләрен саклау мәсьәләләрен чишүгә киртә куелды.

Алай гына да түгел, Рәсәйдә үткәрелгән һәрбер җанисәбен алу кампанияләре чорында бөтен халыкны вак-вак төркемнәргә (типтәр, мишәр, керәшен, барабалы һ.б.) бүлеп, бербөтен татар халкын таркатырга омтылалар.

Бүген бөтен дөньяда милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсе нигездә чишелгән, бу проблема фәнни яктан анализланган, кирәкле чаралар билгеләнгән. Тик менә бер Рәсәйдә генә көчләүдән башка ысуллар юк сыман. Бу проблема кысаларында төпле уйланган,





дәлилләнгән юнәлеш булырга тиеш, әлбәттә. Р.З. Закиров әйтүенчә, «Илнең күпгасырлы тарихы шуны күрсәтә ки, Рәсәйнең гаять зур киңлегендә, күпмилләтле җәмгыять шартларында үзара толерант мөнәсәбәтләргә җитешү җитди көч куюны таләп итә. Милләтара мөнәсәбәтләр проблемасын чишәр өчен шушы катлаулы мохиттә бара торган процессларга дикъкатьле һәм тирән анализ ясау зарур». Менә шундый анализны ясарга хакимияттә теләк кенә юктыр шул.

Хәзер Рәсәйдә дәүләт милли сәясәте турында карарлар кабул ителде ителүен, милли-мәдәни автономияләрдә эшли башлады, шул хисаптан 22 татар милли-мәдәни автономиясе дә. Ләкин, кызганычка каршы, «миллилек җыр һәм бию белән генә, милли киемнәр киеп бәйрәмнәр оештыру белән генә чикләнә, халыкны яңадан торгызуның җитди проблемаларына кагылмый. Мондый «фольклорлаштыру» милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге актуаль проблемаларны чишү юлында көрчеккә алып бара» (Р.З.Закиров). Димәк, башка юллар эзләргә кирәк. Шундый юллар рәтендә автор Рәсәй татарларының һәм башка илләрдәге татар диаспораларының милли хәрәкәтенә укучының игътибарын җәлеп итә, Бөтендөнья татар конгрессының эшләренә анализ ясый.

Татар милли оешмалары XX гасырның 80 енче елларында күренә башлый. 1988 елларда Казанда милли хәрәкәт көчәеп китә, Татар иҗтимагый үзәге корыла. Мондый оешмалар Татарстанның шәһәрләрендә, районнарында, татарлар саны күп булган регионнарда төзелә башлый. Уртак милли максатлар нигезендә Татарстандагы һәм башка регионнардагы, илләрдәге татарлар белән үзара элемтәләр көчәя. «1992 елга татар милли хәрәкәте массакүләм характерга ия була. Әлбәттә, милли оешмаларның сәяси юнәлешләре төрле-төрле була,... әмма алар барысы да бер олы максатка хезмәт итәләр иде, ул да булса- татар дәүләтчелеген торгызу һәм татар халкының милли үзенчәлекләрен саклау» (Р.З.Закиров). Менә шулай башланган татар милли хәрәкәте ныгаеп һәм формалашып, дәүләтнең иҗтимагый-сәяси тормышында лаеклы урын ала. Ләкин соңгы елларда бу хәрәкәтнең билгеле дәрәҗәдә хәлсезләнүе сизелә. Бу очракта объектив һәм субъектив сәбәпләр үзенең ролен уйный.

Р.З.Закировның тирән эчтәлекле һәм нигезле хезмәтенә кыскача анализымны йомгаклап, бу китап - татар тарихчылары, сәясәтчеләре, гомумән, барлык татарлар өчен дә файдалы бер әсбап, диясем килә. Мондагы фактик материал татар милли хәрәкәтенең казанышларын да, югалтуларын һәм хаталарын да аңларга һәм кирәкле бәя бирергә мөмкинчелек ача. Бу исә татар милли хәрәкәтендә киләчәктә нинди юллар белән һәм ничек халкыбызның милли максатларына ирешү ысулларын табарга, аларны практикада кулланырга мөмкинчелек ача.

Милли максат өчен көрәш әле бетмәгән, алда байтак сынаулар да булыр. Әгәр татар үзенең милләтен, милли рухын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен сакларга һәм үстерергә тели икән, аңа шушы материаллар ярдәмче булачак.

***Гриф Хәйруллин, Алматы***

***Фикер №6, 2018 ел***


ОГУП Ирбитский молочный завод
ОБЛАСТНОЕ ГОСУДАРСТВЕННОЕ УНИТАРНОЕ ПРЕДПРИЯТИЕ
«ИРБИТСКИЙ МОЛОЧНЫЙ ЗАВОД»
«УРАЛЬСКИЙ
ЗАВОД»











# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстанның Илеш районындагы Нәҗәде авылында дөньяга килә. Аның балачагы, үсмер еллары Сөн буена урнашкан гүзәл Шәммәт авылында уза. Шул авылның башлангыч мәктәбендә, Аккүз авылының сигезъеллык мәктәбендә, Югары Яркәй мәктәбендә укый ул, Карабаш авылында урта мәктәпне тәмамлый. Шушы елларда ук аның беренче шигырьләре «Башкортстан пионеры», «Маяк», «Ленинсе», «Кызыл таң» газеталарында басылып чыга.

«Маяк» исемле район газетасында әдәби хезмәткәр булып ике ел эшләгәннән соң Роберт Миңнуллин Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Менә шул елларда ул талантлы яшь шагыйрь булып танылa. Газеталарда, «Казан утлары» журналында, «Идел» альманахында шигырьләре басыла. 1970 елда чыккан «Беренче карлыгачлар» исемле яшь шагыйрьләр китабындагы шигырьләре укучыларның игътибарын җәлеп итә. 1973 елда атаклы шагыйрь Илдар Юзеев «Татарстан яшьләре» газетасында Роберт Миңнуллинның иҗатына багышланган мәкаләсен бастыра.

Университетны тәмамлагач, Роберт Миңнуллин «Яшь ленинчы» газетасында эшли башлый, балалар дөньясы белән якыннан таныша. Лирик шигырьләр белән беррәттән балалар өчен дә тәүге шигырьләрен яза. Ул беренче булып өлкәннәр һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы проблемаларны һәрьяклап чагылдыра. Роберт Миңнуллин балалар әдәбиятына, балалар язучыларына багышланган мәкаләләр яза, мәктәпләрдә очрашулар уздыра, ун ел дәвамында Татарстан телевидениесендә «Шигъри тәлгәшләр» исемле тапшырулар циклы оештыра. «Акбай цирк карый», «Җиде абый тай җигә», «Айга очтык» исемле балалар китаплары басылып чыга. 1983 елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен язылган шигырьләргә уздырылган Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыга.

Роберт Миңнуллинның шигырьләренә атаклы композиторлар бик теләп җырлар яза. Ул халык яраткан җырлар язучы актив шагыйрь булып танылa.

Роберт Миңнуллин - тәҗрибәле журналист, танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе. Күп еллар ул «Казан утлары» журналында - бүлек редакторы, җаваплы секретарь, Татарстан телевидениесендә - баш редактор, «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында корреспондент, баш редактор булып эшли.

1990-2014 елларда Роберт Миңнуллин -Татарстанның халык депутаты, Дәүләт Советының Мәдәни һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары һәм башка вазыйфаларны башкара. Ул- Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, төрле елларда Казанда басыла торган байтак журналларның редколлегия әгъзасы, «Татарстан» телерадиокомпаниясенең Попечительләр советы әгъзасы һәм башка вазыйфаларны үз өстенә алган.

Роберт Мөгаллим улы -татар, башкорт, рус телләрендә басылган кырыкка якын китапларның авторы; Муса Җәлил, Абдулла Алиш исемендәге Татарстан Республикасы премияләре, Фатих Кәрим исемендәге Башкортостан Республикасы премиясе, Х.К.Андерсен исемендәге Халыкара премия, Төрекмәнстанның Махумкули медале белән бүләкләнгән. Аңа Татарстанның атказанган сәнгать хезмәткәре һәм Башкортостанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелгән.

Роберт Миңнуллин-Татарстан язучылар берлегенең һәм Журналистлар берлегенең әгъзасы.

==============================

## КОТЛАУ

**Хөрмәтле Роберт Мөгаллим улы!**

Казакъстанда яшәүче татарлар һәм башкортлар исеменнән Сезне олы юбилеегыз белән чын күңелдән котларга рөхсәт итегез!

Казакъстанда яшәүче татарлар һәм башкортлар Сезнең күпьеллык иҗатыгызга соклана, шигырьләрегез һәм Сезнең шигырьләргә язылган җырлар белән без һәрвакыт файдаланабыз, аларны күңелләребездә саклыйбыз.

Сезнең Казакъстанга килүләрегез, милләттәшләр белән очрашуларыгыз барыбызда да тирән тәэсир калдырды. Мондагы татарлар да, башкортлар да Сезне үзенең милли шагыйре дип таный.

Күп еллар буе дәвам иткән иҗатыгызның күркәм җимешләре Сезне татар-башкорт дөньясына гына түгел, башка халыкларга да танытты, шундый югары дәрәҗәдәге әдипнең безнең милләттәшебез булуы белән горурлык хисләре уятты. Иҗатыгызда һәм иҗтимагый хезмәтләрегездә туган халкыбызның мәнфәгатьләрен кайгыртуыгыз иң югары бәягә лаек.

**Кадерле Роберт Мөгаллим улы!**

Олы юбилеегыз- 70 яшькә җитүегез уңаеннан Сезгә иң яхшы теләкләребезне юллыйбыз. Хак Тәгалә Сезне үзенең ярдәменнән аермасын, тормыш юлындагы барлык теләкләрегез, планнарыгыз гамәлгә ашсын!

Киләчәктә дә уңышлы иҗатыгыз дәвам итсен, халкыбыз күңелендә кыйммәтле урын ала торган шигырьләрегез, безне куандырып, көннән-көн, елдан-ел арта торсын!

***Кәримов Т.Ә.*** *- Бөтендөнья татар конгрессы Шурасы рәисенең урынбасары, Казакъстан татарлары һәм башкортлары конгрессының идарә рәисе, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы;*

***Хәйруллин Г.Т.*** *– академик, педагогика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы;*

***Муллашев К.В.*** *- Казакъстан Республикасының дәүләт бүләге иясе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, профессор;*

***Гөзаиров Р.Я.*** *- Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.*

***1 август 2018 ел,***
***Астана ш., Казакъстан Республикасы***

## ТАТАРЛАРЫМ

Роберт Миңнуллинның 2012 елда басылган «Татарларым» исемендәге китабы «Татарларым!..» дигән оран-поэманы һәм күп кенә шигырьләрне үз эченә алган. Китапның исеме җисеменә туры килеп тора. Монда атаклы шагыйрь туган татар халкының үткәннәре, язмышы һәм киләчәге турында сүз йөртә. Бүгенгесе көндә уйланырга сәләтле һәрбер татар зыялысы кебек үк, шагыйрь халкы белән горурлануын да, аның кыенчылыкларын, бәлаларын да, аның мактанырлык, таң калырлык уңай сыйфатларын да, кайбер кире якларын да турыдан-туры ачып бирә. Поэманың авторына карата, чынлап та, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев сүзләренә кушылып: «Уйларыбыз- уртак, фикерләребез- хак»,- диясе килә.

Менә нинди сүзләр белән башлый Роберт Миңнуллин үзенең поэмасын:

*Сезгә дәшәм, газиз татарларым,*
*Алтыннарым минем, талантларым!*
*Татарларым, сезне мактый-мактый,*
*Карлыгыплар бетте тамакларым...*
*Татарларым -алыпсатарларым,*
*Татарларым -укымышлыларым,*
*Татарларым - бал кортлары кебек,*
*Эш атлары кебек тырышларым,*
*Татарларым минем, тапкырларым,*
*Чакматашлар кебек чыдамнарым!*
*Кемнәр соң әле без? Күпме соң без?*-
*Мин очына әле чыгалмадым...*

Шулай итеп, татар сәүдәгә дә оста, укымышлы да, тырыш та, тапкыр да бит! Әмма бүген дә аның санына чыгу кыен икән шул. Уйланырлык та:

*Санап кына бетерерлек түгел*
*Бу дөньяның бөтен татарларын.*

Татарлар бөтен дөньяга таралган. Моңа аптырар урын да юк сыман: татар халкының күп өлеше борынгы татар дәүләтләре җирлегендә гомер сөрә, тарихи мирас нигезендә шул җирләрнең төп хуҗасы саналырга хаклы. Татар халкының төрле якка таралуының тагын бер сәбәбенә игътибарны җәлеп итә шагыйрь:

*Бәхет эзләп, дөнья читләренә*
*Барып чыккан сәйяр татарларым,*
*Кая гына барып егылса да,*
*Торып баскан гаярь татарларым!,*

-ди Роберт Миңнуллин һәм үзенең поэмасын барлык татарларга да багышлый.

Шагыйрь туган халкының тарихына күз сала, аның чыгышын ачыклый, данлы эшләрен барлый. Үзенең олы тарихында *«Утлы чорлар кичкән татарларым»,* -ди Роберт Миңнуллин. Ата-бабаларыбыз арасында скифлар да, татар-монголлар да, сарматлар да, угызлар да, хәзәрләр дә барлыгын, кыпчакларның, сөннәрнең, нугайларның дәвамы булуыбызны да ассызыклый автор. Татар тарихы Болгарлардан, Алтын Урдалардан килүен, заманында татарлар Парижларны, Берлиннарны алучылар булуын да искә төшереп үтә. Сугышта да, тыныч тормышта да татарлар батырлыклар кылган, башка дәүләтләрнең мәртәбәле шәхесләре булган. Татарның тарихи юлы озын һәм катлаулы булуын, такыр да булмаганын искә алып, автор шул юлны *«мең тапкыр изге һәм мактаулы!»,* -дип бәяли.

Татар халкының башка халыкларга гыйлемне һәм изге динебезне таратучы булуын, тыныч һәм тырыш хезмәт белән гомер кичерүен аеруча күрсәтә шагыйрь.

*Теләгәннәр күрер: бер күз салсаң,*
*Бер борылып баксаң үткәннәргә,*
*Татар фәкать изгелеккә дәшкән,*
*Гыйлем нуры чәчкән бүтәннәргә.*
*Кылыч тотып түгел, китап тотып*
*Килгән безнең татар күршесенә...*
*Кайда да бер кояш һәм бер караш,*
*Кайда да эш - татар кешесенә.*

Татарларның башка милләт вәкилләре белән бәйләнешләре, аралашуы турында фикер йөртеп, Роберт Миңнуллин һичкайчан да үз-үзеңне, үз халкыңны онытмаска, үз йөзеңне югалтмаска чакыра: татарлыгын да хәтерләми торган милләттәшләренә үпкә белдерә. Башка халыкларга әверелгән, иманыннан, диненнән һәм теленнән язган татарлары өчен ачына. Менә шуларга да автор:

*«Сез дә безнең үзебезнең татар, кемнәр генә булсагыз да, сезгә минем сүзләрем»,-* дип мөрәҗәгать итә.

*...Казахлашып, кыргызлашып беткән,*
*Поляклашып беткән татарларым:*
*Башкаларга, башка халыкларга*
*Яраклашып беткән татарларым...*
*...Башкорт булып йөргән татарларым,*
*Татар белән катнаш башкортларым;*
*Татардан да, башкорттан да киткән,*
*Урыслашып беткән маңкортларым...*

Ярымтатар-ярым башка халык вәкиленә әйләнгән кешеләр өчен шагыйрьнең җаны, үзәкләре өзгәләнә. Кырымдагы татарларның хәле аның бәгырьләрен телә. *«Урыслашып бетмисезме әле»,*-дип борчыла ул, Урал, Себер, Әстерхан, Ижау, Нижгар, Самар, Себер, Ырынбур татарларына мөрәҗәгать итеп. Кытай белән Казах җирендәге, Мордва һәм Чуваш илендәге, Мари илендәге, Фин илендәге татарлардан: *«Сез татармы әле?»,*-дип сорый шагыйрь. Ул Балтыйк буендагы, Бакудагы, Мәскәүдәге һәм башка җирләрдәге милләттәшләренең язмышы, киләчәге турында уйлый. Кайда гына булмасын, татар милли хәтерен сакларга тиеш:

*Без хәтерсез түгел, татарларым!*
*Татар барда һәрчак хәтер булсын!..*

Тарих юлларына карасак, татарлык хәтере халыкта һәрвакыт тулысынча сакланган икән, диярлек түгел шул. Никадәр татар дәүләтләре корылып, чәчәкләнеп тә, соңрак дошманнар кулына төшүе -үзе нәкъ шушы хакта сөйли түгелме? Халкыбызның данлыклы тарихына күз салганда, аның бердәмлек мәсьәләсендәге кимчелегенә шагыйрь дә игътибарсыз калалмый:

*Кемнәр генә булыр идек хәзер*
*Бер ырулы булсак әгәр дә без?!*

Татарның мишәре дә, типтәре дә, керәшене дә бар, башкорт татарлары, Кырымдагы татарлар бар һәм башкалар,һәм башкалар. Беренче нәүбәттә, шуларның бердәмлеге кирәк. Роберт Миңнуллин бөтен җаны-тәне, милли рухы, иҗат көче белән үзенең туган халкын бердәмлеккә чакыра: *«Таркалырга безнең хакыбыз юк!»*,- дип оран сала шагыйрь. Моның өчен үз-үзеңне, үз халкыңны яратырга кирәк, татарлыгыңны күз карасы кебек сакларга кирәк, ватанпәрвәр һәм татарпәрвәр булу зарур, - дип йомгаклый ул сүзләрен.

*Безнең башка барыр юлыбыз юк...*
*Юлыбыздан язмыйк, татарларым!*
*Ходай безгә шушы юлны язган,*
*Юлдан язу- язык, татарларым!..,*-дип кисәтә шагыйрь укучыны.

Шулай да, әгәр татар халкы, нинди афәтләрне үтеп, үзен-үзе аерым бер үзенчәлекле милләт рәтендә саклап кала алган икән, димәк, аның киләчәккә дә өмете бар. Шушы өметне шагыйрь түбәндәгечә белдерә:

*Безне алда ниләр генә көтә?!-*
*Белә алмабыз шул теләсәк тә...*
*Без яшибез бүген! Татар килеш*
*Без яшәргә тиеш киләчәктә!*

Әлбәттә, бу мәсьәләне хәл итүдә кирәкле нәтиҗә булуы-булмавы, беренче нәүбәттә, татарның үзенә бәйле. Бу хакта Роберт Миңнуллин менә нинди теләкләрен укучыга юнәлтә:

*Без үзебез әгәр аттырмасак,*
*Кем аттырыр безнең татар таңын?!*
*Без үзебез әгәр сакламасак,*
*Кемнәр саклар безнең татар җанын?!*
*Без үзебез әгәр күтәрмәсәк,*
*Кем күтәрер безнең татар данын?!*
*...Син югалтма, татар, үз кыйблаңны,*
*Кычкырып әйт, татар, үз сүзеңне!*
*Якла, Ходай, якла татарыңны!*
*Сакла, татар, сакла үз-үзеңне!*

Роберт Миңнуллин үзенең оран-поэмасын түбәндәге сүзләр белән тәмамлый:

*Халкыбызның киләчәген уйлыйк,*
*Кабатламыйк тарих хаталарын!..*
*Мин сүземне әйттем! Язмышыбыз*
*Үзебездән тора, татарларым!*
*Газиз та-тар-ла-рым!*

Шушы тирән мәгънәле, киң эчтәлекле поэмага лаеклы бәя бирү бик үк җиңел эш түгел. Шуңа күрә без тагын М.Ш.Шәймиевның сүзләренә таяныйк: «Моннан берничә ел элек ял вакытында телевизордан Роберт Миңнуллинның «Татарларым» дигән поэмасын тыңлап та, күңелемә шулай ук рәхәтлек, рух

күтәренкелеге алган идем. Дөресен әйтим, халкыбызның язмышы, тарихы турында тирән уйларга бирелеп, татар булуым белән чиксез горурланып, якты хисләр кичереп утырдым мин ул чакта»...

Китапта китерелгән шигырьләрнең дә байтагы милләтебез мәсьәләсенә бәйләнгән. Мисал өчен, «Биләр», «Алтын Урда», «Кылганнар» исемендәге һ.б.ш. шигырьләрен атап үтәргә була. Борынгы татар дәүләтләреннән, аларның бөек шәһәрләренән калган харәбәләрне күреп, шагыйрь сагышлана, аның күңелендә кызгану да, үкенеч хисләре дә уяна. Шулай да автор киләчәккә өмет белән карый:

*Эзлим сине*
*Күмер-көлдән,*
*Эзлим сине*
*Килер көннән.*
*Мин табармын*
*Сине шунда,*
*Алтын Урда,*
*Алтын Урда!*

«Кол Шәриф» исемле шигырендә Роберт Миңнуллин туган халкының тарихы белән горурлануын, күңелләр сыкрарлык нинди авыр чорлар килгәндә дә татарның, кыенлыкка бирешмәстән, азатлыкка омтылуын алгы планга куя:

*Тарихыбыз -гыйбрәтле дә,*
*Тарихыбыз- бөек тә!*
*Башларыбыз- иелмәгән,*
*Карашыбыз- биектә!*
*....Без- горур да, без- мәгърур да,*
*Без кол түгел, Кол Шәриф!*

Халыкның үткән тарихында нинди фаҗигалар булуына ишарә ясап, Муса Җәлилнең һәм җәлилчеләрнең хәтерләрдә мәңге сакланачак батырлыгын искә алып, Роберт Миңнуллин: *«Татар башы башка киселмәсен!»,*- дип оран сала, *«Без бүген дә җәлилчеләр кебек,... Җәлил хәлендә»,* - дип халыкның язмышы өчен ачынуын белдерә.

*Һәр татарның җаны тулы яра,*
*Булмаса да яра тәнендә.*
*Татарга да кояш чыгып ала,*
*Тарих бит ул аклы-каралы.*
*...Ачы да соң татар язмышлары!*
*Бер уйласаң, исең китәрлек...*

«Чиратмы әле безгә?!» дигән шигырьдә (Рафаэль Мостафин истәлегенә багышланган) Роберт Миңнуллин җәлилчеләр гомеренең безнең өчен үрнәк булырга тиешле икәнлеген тагын да ассызыклый. Җәлилчеләр мисалына бәйләп, ул татар халкының киләчәгенә тагын да өметләрен белдерә:

*Җәлилчеләрдәге иман*
*Бездә бетмәгәндер бит?*
*Тарихтагы татар чоры*
*Әле үтмәгәндер бит?*
*Күрербез бит татарның да*
*Үз таңын аттырганын!..*
*Онытмас, татар, онытмас*
*Үзенең батырларын!*

«Барыбер югалмадык!» дип, туган халкы өчен горурлана шагыйрь. Татарның башына нинди генә сынаулар төшсә дә, ул бирешмәгән, сынмаган, сыгылмаган; почмактан атсалар да, үтерсәләр дә, мең тапкыр янасалар да, татар халкы үзен-үзе сакларга сәләтле булган. Татар халкының шундый сыйфатларына соклануын, шуның өчен горурлануын шагыйрь онытылмаслык шигъри юлларда күрсәтә:

*Сынарлык чаклар да булды-*
*Сынмадык, сыгылмадык.*
*Кимсеткәндә кимсенмәдек,*
*Екканда егылмадык.*
*Сыналдык, ләкин сынмадык!*
*Сыналдык-сынатмадык!*
*Менә ул без! Үзебезне*
*Барыбер югалтмадык.*

Киләчәктә дә татар халкы үз мәнфәгатьләрен үзе кайгыртырга тиеш,- дигән тезисны тагын алга сөрә шагыйрь. Моңа мисал итеп, «Сәясәт» исемендәге шигырьне алыйк. «Мәскәүләр югарыдан кушып кына яталар; Мәскәү убырларына күпме җибәрсәң дә җитмәс, мондый хәлдә соңгы ыштаныңны да салдырып алырлар»,- дип бәяли хәлне шагыйрь. Мәскәү белән Казан арасынданы мөнәсәбәтләрне. Моңа каршы тора белү-бу татарларның үзләренә бәйле:

*Мәскәү безне кыса, дибез,*
*Кыстырткачтын кыса ул.*
*Өстәвенә кыскан чакта*
*Кычкырмаска куша ул.*
*...Күпме генә кысылсак та,*

*Киерелгән безнең түш...*
*Кысу- мәскәүләрнең эше,*
*Ә кыстыртмау-безнең эш!*

Азатлык юлында күп киртәләр булачагын искә алып, шуларны ерып чыгар өчен халкыбызның яңа батырлары туачагына һәм гадел көрәшкә чыгачагына өмет белдерә шагыйрь. Мисал өчен, «Батырлар җыры» дип аталган шигырьдә шул өметләр менә ничек күрсәтелгән:

*Иртә әле- тынмаячак,*
*Бер дә тынып тормаячак*
*Батырлар җыры.*
*Батырларга яу бетмәгән,*
*Үтмәгән әле, үтмәгән*
*Батырлар чоры!*
*Батырлар чоры!*

Шундый нәтиҗәгә килеп, Роберт Миңнуллин татар халкының киләчәгенә тагын да өметләр тудыра:

*Татарны йөртә өмете,*
*Яшәтә аны өмет.*
*Хәлләребез алай бик үк*
*Өметсез түгел кебек.*
*... Юк өметсез түгел татар-*
*Өметләр дөрләп ала.*
*Соңгы өмет тә өзелсә,*
*Үләргә генә кала* («Татар өмете» исемле шигырь).

Туган халкының ямышы турында уйланулар, аның киләчәге хакында борчылулар шагыйрьне, табигый ки, яңадан халык бердәмлеге мәсьәләсенә алып кайта. Аерылышкан ике бертуганнар турындагы халык бәетенә ишарәләп, Роберт Миңнуллин: «Сак-Соклар без...»,- дип ачына.

*Инде күптән Сак-Соклар без...*
*Түзәрлекләр калмады.*
*Кемнәр безне аерды соң?*
*Кемнәр безне каргады?*
*Татарларым- газизләрем-*
*И Сокларым- Сакларым...*
*Сагынам мин барыгызның*
*Бергә булган чакларын...*

Татар халкының бердәмлеге хакындагы уйлар бу халыкның таралып яшәве күренешенә барып бәйләнә. Шагыйрь татарлар төркемнәренең бер-берсеннән бик ерак булып, бүленеп калуларына да игътибар итә:

*Ырынбур далалары...*
*Бу татар балаларының*
*И ерак аралары,*- ди Роберт Миңнуллин «Ырынбур далалары» исемле шигырендә. Икенче бер шигырьдә исә *ул:*
*Бу татар, һай, сибелгән...*
*Рәсәйнең бөтен картасы*
*Татар белән чигелгән,*- дип раслый.

Үзенең бер шигырен Роберт Миңнуллин «Татар белән Себер тулган» дип исемләгән. Монда ул тагын татарларның бөтен дөньяга таралганлыгына, шунда да үзенең татарлыгын саклый алуына игътибар итә:

*Татар кайда да татар ул,*
*Татарсыз Себер дә юк:*
*Татарсыз җирне, гомумән,*
*Ишеткәнем бер дә юк.*

Яшел Үзәндә фин татарларына укылган шигырендә шагыйрь таралган татарларның сагышлы күңеленә укучының игътибарын тарта:

*Сагынырга туган татар-*
*Чәчелгән, таралган ул.*
*Сагынып, саргаеп кына*
*Яшәргә яралган ул.*

Әлбәттә, татарларның таралып, башка халыклар арасында тормыш коруы тагын бер күренешкә сәбәп була. Ул да булса, татарларның татулыгы, бүтән милләтләр белән уртак тормыш кора белүе нәтиҗәсендә татарлар *«Үрчетә чит милләтләрне татар башы белән»*. Шуның өчен дә бит:

*Күпме милләт карап тора*
*Татар күзе белән,*
*Күпме милләт балкып тора*
*Татар йөзе белән!*
*Күпме милләт яшәп ята*
*Татар каны белән,*
*Үзе- үзбәк, урыс, башкорт...*
*Татар - җаны белән* («Татар» дигән шигырь).

Татар халкының саны үсмәвенә, кайчагында хәтта кимеп тә калуына сәяси шартлар да сәбәп булырга мөмкин. Мондый күренеш бигрәк тә Башкортостанда яшәүче татарларга хас. Башкортостанда туып үскән атаклы татар шагыйре Роберт Миңнуллин бу темадан





читкә тайпылалмый, әлбәттә. 2002 елгы җанисәбеннән соң юкка чыккан ике йөз меңнән артык Башкортостан татарларына мәрсия рәтендә ул «Кая югалдыгыз, татарларым?!» исемендәге шигырен иҗат иткән. Монда ул кичә генә исән булган татарларның юкка чыгуына гаҗәпләнә, шул хәлнең сәбәпләре белән кызыксына. Сезгә ни булды: аттылармы, астылармы, төрмәләргә яптылармы, әллә үзегез үзегезне саттыгызмы?- дип ачынып сорый шагыйрь.

*Мин беркемне гаепләмим монда,*
*Мин бит бары авыр сулыйм гына.*
*«Кая югалдыгыз, татарлар?» -дип,*
*Мин бит сездән бары сорыйм гына.*
*Кая булдыгыз сез, татарларым?*
*Сез кайларга китеп югалдыгыз?*
*Канлы гасырлардан исән чыгып,*
*Ничек кенә болай булалдыгыз?*

Роберт Миңнуллинның атаклы тарихи шәхесләребезгә багышланган шигырьләре китапта аерым урын алып тора. Шундый шәхесләребезгә соклануын да, аларның фидакарь хезмәтен югары бәһалавын да, шундый шәхесләрне үстергән халкы өчен горурлануын да яшерми шагыйрь. Үзенең укучысын ул шундый бөек милләттәшләребездән үрнәк алырга чакыра. «Мәгърифәтче Каюм», «Утыз Имәнине укыганда туган уйлар», «Без кайтырга тиеш!», «Халык шагыйрьләре», «Китмә, сандугач», «Фәнис Яруллин», «Мөхәммәт дигән атың бар», «Җырны булмый үтереп», «Син үзеңчә яратырга хаклы», «Афәрин» һ.б. шигырьләр шундыйлардан. Халкының атаклы шәхесләрен чын күңелдән ышандыра шагыйрь:

*Сезнең батырлыкка халык*
*Баш ияр таңга калып!*
*Онытмас сезне чал тарих,*
*Онытмас сезне халык!*

Роберт Миңнуллинның «Татарларым» исемле китабы - укучыны дәртләндерә торган, өметләндерә торган, халкы белән горурландыра да торган китап. Бу - милләтпәрвәр, татарпәрвәр шәхесләрне тәрбияли торган китап.

Менә шушы гүзәл китабына сокланып, якташым Роберт Мөгаллим улына ихлас күңелдән рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар теләп, аның киләчәк тә дә, тагын- тагын да шундый әсәрләр язачагына иманым камил.

***Гриф Хәйруллин, Алматы***











## КАЗАКЪСТАНДА САБАНТУЙ БӘЙРӘМНӘРЕ

### *СЕМЕЙДА БАЛАЛАР САБАНТУЕ*

Семей шәһәрендә Беренче шәһәр «Балалар Сабан туе» узды! Бәйрәмне «Хак» Иртыш буе татарлар һәм башкортлар Ассоциациясе, Татар сәнгать мәктәбе, Семей шәһәренең мәгариф һәм эчке эшләр бүлекләре, Семей шәһәре үзәк ял паркы, "Кечкенә Апуш" татар балалар клубы, Чернышевский исемендәге 1 - гомуми белем бирү мәктәбе, "Мирас" татар яшьләр үзәге оештырды. Әлеге чара Халыкара балаларны яклау көненә һәм Астананың 20-еллыгына багышланды.

Чарада ике дистәдән артык иҗади зоналар: декоратив-гамәли иҗат буенча ике мастер-класс, ачык һавада татар биюе буенча мастер-класс, милли татар стилендә оештырылган фотозоналар, аквагрим, акбур белән асфальтта татар бизәкләрен ясау, әкият зонасы (татар халык әкиятләрен уку), рәсем конкурслары, розыгрышлар, милли уеннар оештырылды. Шулар һәм фудкорт, Татар сәнгать мәктәбе укучылары катнашуында концерт программасы, музыкаль конкурс, шигъри конкурс барлык кунакларның игътибарын үзенә тартты. Күркәм бүләк - татар биюе белән ятим балалар өчен һәм әти-әнисез калган балалар өчен эшләп килгән Көнчыгыш Казакъстан мәктәп-интернат укучылары тамашачыларны котлады.

Балалар Сабан туенда һәрбер кеше үзенә ятышлы шөгыль таба алды, һәрбер бала бүләкле булды. Оештыручылар исә тагын бер кат үзләренең бердәмлекләрен, көчен, иҗадилыкларын һәм балаларны яратуларын күрсәттеләр. Бөтендөнья татар конгрессына, Татарстанның «Татмедиа» медиакомпаниясенә татар балалар китапларын һәм журналларын җибәргән өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез!

***Диләнур Ахунҗанова, Семей***










==============================================================

***АЛМАТЫДА САБАНТУЙ***

Алматы шәһәрендә гөрләп сабантуй үтеп китте. Бәйрәм һәркемнең күңелендә якты эз калдырды, йөрәкләрдә татар җырларының моңнары, җырлаганда халыкның сәхнә алдына чыгып биюләре йөрәкләрне җилкендерде.

Бәйрәм күңелле үтсен өчен бик күп оештыру эшләре алып барыла. Башта сабантуй үткәрә торган җирне карыйлар, сәхнәне бизиләр, аппаратура куялар, көрәшне уздыру өчен сарык һәм төрле призлар, бүләкләр, сөлгеләр сатып алына, спорт инвентарьлары алып киләләр, төрле уеннар уздыру өчен бүләкләр, призлар сатып алалар. Һәм аларны уздыру өчен бар кирәк - яракны алдан әзерләп куялар, милли киемнәр күргәзмәсенә милли күлмәкләр, чигелгән калфаклар,чигелгән киндер сөлгеләр куела. Ә инде милли ашлар күргәзмәсенә татарларның төрле-төрле милли ризыклары пешерелә. Сабантуйда менә шушы әзерлекнең барысын да оештыручылар - бу Алматы шәһәрендәге татар - башкорт иҗтимагый - мәдәни үзәгенең рәисе Гизатулин Рашид Рахматуллович һәм идарә әгъзалары Газизов Әмир, Вафин Илмират, Маркина Фагилә, Махмудов Хади, Мухамеджанова Раяна, Шарипова Виктория.

Бәйрәмне зур хәзерлек белән яхшы итеп оештырганнары өчен аларга зур рәхмәтебезне җиткерәсебез килә, аларга саулык- сәламәтлек, бәхетле тормыш, зур уңышлар телисебез килә.

Сабантуй бәйрәмен Казакъстандагы татарлар һәм башкортлар конгрессы рәисенең урынбасары Хайруллин Гриф Тимурович һәм татар - башкорт иҗтимагый- мәдәни үзәгенең җитәкчесе Гизатулин Рашид Рахматуллович ачтылар, җыйналган халыкны бәйрәм белән чын күңелдән котладылар, аларга тормышларында шатлыклы гомер, бәхет, сабантуй бәйрәмен күңелле итеп үткәрүне теләделәр. Имам Канат Талгат улы һәм Азат хәзрәт сабантуйга фатиха бирделәр, изге догалар укыдылар. РФ Генераль консуллыгының консулы Переверзева Ирина Владимировнага бәйрәмгә килгән халыкны җылы котлады һәм бәйрәмне күңелле итеп үткәрүне теләде. Казакъстан халыкы Ассамблеясеннән сабантуй бәйрәме белән Мансуров Казбек Владимирович котлады.

Татарстан Президентының котлау хатын Казан шәһәреннән кунак булып килгән җырчы һәм композитор Булат Җиһаншин укыды һәм халыкны Президент исеменнән кайнар котлады.

Алматы шәһәрендәге татар - башкорт иҗтимагый - мәдәни үзәге җитәкчесенең киңәшчесе, күп җәмәгать эшләрен алып баручы, бәйрәмнәрне үткәрүче, татар милли киемнәренең күргәзмәләрен, татар милли ашларының күргәзмәләрен оештыручы, һәрвакытта үзәктә кунакларны каршы алучы Шарипова Виктория Фазыловна мактау грамотасы һәм акчалата бүләккә лаек булды. Шулай ук үзәктә күп җәмәгать эшләрендә катнашучыларны, татар якшәмбе мәктәбе укытучыларын һәм гарәп телен өйрәтүче укытучыларны Махмудов Хади Шарифулловичны, Каипова Венера Гаяновнаны, Галиева Сания Сәмигулловнаны, Каипова Равза Талгатовнаны бәйрәм белән котлап, аларга да грамоталар һәм акчалата бүләкләр тапшырдылар.

Татарча көрәшне правление әгъзасы тренер Абдуллин Халил алып барды. Җыйналган халык бик кызыксынып көрәшчеләрне хуплап көч биреп торды. Көрәшкә балалар һәм яшүсмерләр арасында сигез кеше, зурлар арасында 15 кеше катнашты. Беренче урынны Сыдыков Зуфар яулап алды. Аңа сарык бүләк итеп бирелде. Икенче урында Хасанов Джамшит, өченче урынны Хасанов Алим яулап алды. Аларга акчалата бүләк һәм призлар тапшырылды.

Сабантуйда милли ашлар күргәзмәсе оештырылды. Монда инде үзәккә йөрүче хатын-кызлар үзләренең осталыгын күрсәтте. Бу күргәзмәгә Акчурина Рамзия җаваплы иде. Нинди ашамлык икәнлеге язып куелган, рецептлары күрсәтелгән, болар: чәк -чәк, гөбәдия, күп төрле бәлешләр, пәрәмәч, вак бәлеш, самса, шәңгә, кыстыбый, печенье һәм башкалар һәм башкалар. Безнең үзәккә йөри торган, шушы тәмле -тәмле пирогларны пешерүче хатын -кызларның барысына да грамоталар һәм бүләкләр бирелде.

Ә милли киемнәр күргәзмәсен Галимбаева Вадига оештырды. Монда күз явын алырлык итеп бисер белән үз кулы белән чигелгән калфаклар, түбәтәйләр, милли күлмәкләр, балалар күлмәкләре, милли киемдәге курчаклар, кулдан ясалган беләзекләр, йөзекләр, татар китаплары күрсәтелгән иде.

Сабантуй - гаилә бәйрәме. Бәйрәмдә төрле - төрле уеннарны Мухамеджанова Раяна оештырды. Асфальтта рәсем ясау- «Минем гаилә» конкурсы үткәрү, кашыкка йомырка салып йөгерү, көянтә белән су ташу, биек баганага шуышып менү һәм башка уеннар уздырылды. Уеннарда балалар, шул хисаптан, детдомнан килгән балалар катнашты. Һәр балага бүләкләр, призлар тапшырылды.

Сабантуй бәйрәмен алып баручы Галиева Сания халыкның яраткан «Умырзая» татар җыр ансамблен сәхнәгә чакырды һәм алар «Сабан туе җыры», «Күбәләгем» татар халык җырларын башкарды. Халык ансамбльне яратып тыңлады.

Башкалабыз Казан шәһәреннән килгән, яратып, көтеп алынган зур кунаклар- татар артистлары чыгыш ясады. Татар эстрадасының йолдызы, танылган җырчы, талантлы композитор, конферансье, «Татар җыры» халыкара фестиваленең «Алтын барс» премиясе лауреаты, ТНВ һәм «Болгар» радиосының «Милли музыка» премиясе лауреаты Булат Җиһаншин үзе язган һәм башка композиторларның җырларын җырлады. Йөрәктән чыккан җырлары, моңнары белән халыкның күңелен яулады һәм үзенең җырларына халыкны биетте. Халык аны алкышлап каршы алды.

«Алтын барс» премияләре һәм «Манзара» халык премиясе иясе, татар эстрадасының йолдызы, талантлы яшь җырчы Эльвира Хамматова үзенең җыр - моңнары белән халыкның күңелен яулады, җырларына халыкны биетте. Артистканы алкышлап каршы алдылар. Эльвира Хамматова үзенең әле генә Себер, Урал якларында үзенең концертлары белән, Татарстанда театрлаштырылган концертлар белән чыгыш ясаганын әйтте.

Кунакларыбызга- ике артистка да иҗади уңышлар, зур сәламәтлек, шатлык, бәхет, имин юлллар, зур сәхнәләрдә чыгыш ясауларын теләп бүләкләр тапшырылды.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Халыкара татар җыры «Җиде йолдыз» фестиваленең лауреаты, 50 ел буена сәхнәдә татар, казах, русча җырлар башкаручы, Казакъстан филармониясенең солисткасы Сайбулатова Галибә үзенең йөрәктән чыккан көй-моңнары белән халыкны шатландырды.

Сәхнәдә «Мой голос» дип аталган рус телендә җыр яңгырады. Алсу Шамсутдинова Астана шәһәре җыр «Көн -шуак» фестиваленең лауреаты, беренче урынны алган, Алматыда «Салют талантов» җыр конкурсында җиңеп чыгып беренче урынны алган. «Син сазыңда уйнадың» исемле музыкаль композицияне Усманова Альмина (флейтада) һәм аның укытучысы Черняева Ольга Равильевна бергә башкардылар.

Сәхнәдә тагын да «Умырзая» ансамбле татар халык җырлары «Талы- талы», «Әй, былбылым», башкорт халык җыры «Әй - ли гөлкәем» не башкарды. Баянда Халыкара һәм Республика конкурслары лауреаты Конысбеков Мейрамбек уйнады. Ул баян классы буенча консерваториядә укыган, Курмангазы исемендәге дәүләт академик халык уен кораллары оркестрының баянчысы. Аның исеме «Лучшие в образовании» энциклопедиясенә кертелгән, ул «За вклад в развитии образования» медале белән бүләкләнгән. Қонысбеков Мейрамбек танцеваль композицияләрне (Аргентинское либер танго, «Тико - тико») башкарды.

Сабантуй бәйрәмен алып баручы, танылган җырчы, Алматыда шәһәрендә Майра Уаликызы исемендәге Халыкара конкурста катнашучы, баянда уйнап татар һәм казах җырларын башкарган, Урта Азия халыклары традицион мәдәнияте Халыкара фестиваленең дипломанты, «Иртыш моңнары» Халыкара җыр фестиваленең 2013 елда лауреаты Галиева Сания «Сагындым авылымны», «Алым жәл түгел сиңа» җырлары белән халыкның күңеленә хуш килде.

Сабантуйның концерт программасы бөек татар шагыйре Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» җыры белән тәмамланды. Видеоканал «Казахстан» концерт программасын, татарча көрәш, сабантуйда оештырылган уеннарны, милли ашлар күргәмәсен, милли киемнәр күргәзмәсен видеотасмага төшерде. Сабантуйны оештыручыларга, сабантуйда катнашучыларга чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

***Галиева Сания, Татар якшәмбе мәктәбе укытучысы, Алматы***






САБАНТУЙ КОТЛЫ


AIRPLANE







## *САБАНТУЙ ПОИСТИНЕ НАРОДЕН*

*Традиционный ежегодный «Сабантуй-2018» в 18-й раз собрал друзей в минувшее воскресенье на сопке Букпа в Кокшетау.*

Много добрых дел предшествовали нынешнему сабантую: благотворительный вечер татарской песни с участием артистов из Татарстана для сбора средств на установку памятника Мусе Джалилю в Кокшетау, осенний праздник «Чәк-чәк бәйрәме» на приз акима города и именитых семей диаспоры региона, фестиваль-концерт «Мин яратам сине, Кокшетау». Вспомним также, празднование в Костанае «Сабантуя-2017» с участием Президента Республики Татарстан, поездку наших активистов на VI съезд Всемирного конгресса татар. Состоялись театральные спектакли Буинского театра сатиры, благотворительный концерт эстрадного певца, композитора Рената Ибрагимова. Установлена мемориальная доска на доме И.Н.Салахова. Изданы книги «Забвению не подлежит» (посвященная жизни и творчеству И.Н.Салахова), «Родительский дом» (памяти своим предкам и рассказы о казахстанских татарах и татарской диаспоры в Кокшетау), автором которых является ветеран казахстанской журналистики Лариса Аитова. Завершен перевод на казахский язык романа-хроники «Черная Колыма» И.Н.Салахова.

Проведены мероприятия, посвященные памяти М.Джалиля в феврале и Г. Тукая в апреле нынешнего года. Ведется активная работа с Академией наук РТ (институт истории им. Ш.Марджани) об истории татар Кокшетау и Акмолинской области (автор- к.и.н. г. Казани Зуфар Махмутов). А сколько еще планов впереди на весь год!

Отличное настроение, заряд здоровой энергии сопровождали всех участников «Сабантуя-2018», приехавших в минувшие выходные в качестве гостей и зрителей из Астаны, Петропавловска, Степногорска и Казани. Свежий воздух нашей благодатной, гостеприимной земли был пропитан вкусными ароматами татарской выпечки, горячего чая и шашлыка. Радушно встречала всех желающих хозяйка татарского дворика, она же преподаватель татарского языка воскресной школы «Шаңырақ» Гаухар Аминова. В новой ипостаси выступила журналист Лариса Аитова, представив на развернувшейся рядом ярмарке Союза мастеров декоративно-прикладного искусства при Акмолинской ассамблее народа Казахстана свои творческие работы: оригинальные вышитые картины, сшитые hand-made ак калфаки, свои книги. Здесь же мастерица Гульнара Орынбаева предлагала экологически чистые изделия (головные уборы, жилеты) из валяной шерсти по очень демократичным ценам. Радовал детвору тренер детско-юношеской конноспортивной школы с. Красный Яр Жаслан Танкыбаев, устроив прогулки на резвом скакуне по живописным уголкам Букпы. Жаркое состязание на ковре не оставило равнодушными не только мужчин, даже дамы активно поддерживали борцов татарча курэш за право быть первым и получить главный приз - живого барашка. Батыр сабантуя, мастер спорта по греко-римской борьбе ШВСМ Константин Штефанов унес его на себе. Его достойный соперник, кандидат в мастера спорта Жаслан Типогаров выиграл набор посуды для своей семьи.

Учащийся колледжа им. Акана серэ Николай Савельев к всеобщей радости молодежи одолел высоту необычно украшенного 10-метрового столба и «спас» бойкого петуха. Девушки и парни соревновались в армрестлинге, перетягивании каната, беге с коромыслами и в мешках, играли в «Ручеек». В ожидании артистов из Казани публику развлекали участники и солисты татаро-башкирских центров г.г. Астаны, Петропавловска, Степногорска. «Мы в первый раз выступаем в вашем городе, и нас тепло здесь встречают. 1 июля ждем всех кокшетауцев на 30-летний сабантуй, который пройдет в парке культуры и отдыха», - приглашают зампредседателя татаро-башкирского общественного центра «Дуслык» Мнира Куспанова, солистка ансамбля «Ляйсан» Гульсина Бикчентаева и певец Ринат Шамсутдинов из Петропавловска. Душевно пели мама и дочь, активистки из Степногорска Руфия и Марьям Галиевы.

И, наконец, на сцену вышли ожидаемые гости из г. Казани - лауреаты международных конкурсов и фестивалей Наиль Набиуллин и Анжелика Вакилова. Солистка Дома дружбы народов Татарстана г. Казани очаровательная Анжелика передала благодарственные письма от Президента РТ Р.Н. Минниханова председателю центра Рафаилу Сулькарнаеву, а также активистам - Министерства культуры Татарстана. Артисты, исполнив несколько татарских хитов, зарядили всех отличным настроением. А под песню «Синий туман» образовавшиеся спонтанно танцевальные пары абиек и бабаев показывали пример молодым.

Запомнилась всем проникновенная песня «Қамажай» в исполнении солисток ДК «Достар» Айданы Жаркынбаевой и Алены Тыщенко, а также громкими аплодисментами приветствовали уже известный в Кокшетау ансамбль «Таволга».

***Вероника Бурда, Кокшетау***

## ВСТРЕЧА С В.Г.ШАЙХРАЗИЕВЫМ

Город Алматы в этом году посетила татарстанская делегация, которую возглавлял заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, председатель Милли Шуры Всемирного конгресса татар Шайхразиев Василь Габделгаязович. Он встречался с городскими властями, а также интересовался деятельностью татарских и татар-башкирских культурных центров. В настоящее время в городе действуют три таких центра: татарский, татаро-башкирский и центр «Ильдаш».

Делегация из Казани посетила татарско- башкирский культурный центр. Во встрече с делегацией участвовали председатель центра Гизатулин Р.Р., а такаже члены правления центра. Делегация оценила концертные номера, а также выставку национальных татарских костюмов. Здесь были представлены вышитые льняные полотенца, татарские калфаки, тюбетейки с ярким национальным орнаментом, куклы в национальном одеянии. Все это сшила и подготовила Галимбаева В.З. Посетили татарскую библиотеку, ознакомились с деятельностью центра.

В нашем центре проводятся занятия по изучению татарского языка, арабской графики. Учителя: Махмудов Х.Ш., Каипова В.Г., Галиева С.С., Каипова Р.Т. Действует вокальная группа «Умырзая». В спортивном зале занимаются дзюдо и национальной борьбой (Абдуллин Х.Х.), проводятся шахматные турниры (Абдуллаханов А.), работает кружок вязания (Петракова А.). Проводятся мастер - классы по татарской кулинарии. Организатор и информатор всех этих меропрятий- советник председателя центра Шарипова В.Ф. Нашу работу делегация оценила высоко.

В тот же день члены татарстанской делегации и члены правления центра посетили концерт казахской и татарской классической музыки, организованный по инициативе Р.А.Абдулхаликова. В.Г.Шайхразиев поздравил зрителей с таким мероприятием.

Казахский академический симфонический оркестр исполнил классическое произведение «Сабантуй» Назиба Жиганова. Из балета «Шурале» композитора Фарида Яруллина исполнили танец ведьмы, танец сватов, праздничный танец и другие. Оркестром дирижировал талантливый руководитель этого оркестра Нуржан Байбусинов, ранее работавшей в театре оперы и балета имени Мусы Джалиля в Казани, в Мариинском театре Санкт- Петербурга, в турецком оперном театре.

Народная артистка Республики Казахстан, солистка театра оперы и балета (г.Астана) Майра Мухаметкызы исполнила арию из оперы татарского композитора Назиба Жиганова «Алтынчеч», написанной на либретто поэта Мусы Джалиля. Напомним, что первая постановка оперы «Алтынчеч» была в Казанском театре оперы и балета 9 июня 1941 года. Знаменитый «Казахский вальс» композитора Латиф Хамиди в исполнении Майра Мухаметкызы зрители встретили восторженно и вручили цветы певице. Из оперы «Абай» композиторов Ахмета Жубанова и Латиф Хамиди она исполнила арию Ажар.

Заслуженного артиста Республики Татарстан Филюса Кагирова зрители встретили восторженно. Он исполнил в сопровождении оркестра песни Рустама Яхина «Китмә, сандугач» «Онытa алмыйм», а также песню из драмы «Наемщик» композитора Салиха Сайдашева. Песню «Мин сине шундый сагындым» он исполнил акапелла.

В конце концерта Филюс Кагиров и Майра Мухаметкызы вместе с зрителями испонили песню «Туган тел» на слова великого татарского поэта Габдуллы Тукая. Концерт всем понравился.

***Галиева Сания, Алматы***

## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО КИНО

С 1 по 7 июля в Астане прошел XIV Международный кинофестиваль «Евразия». В числе почетных гостей кинофестиваля были исполнительный директор Казанского международного фестиваля мусульманского кино, руководитель «Татаркино» Миляуша Айтуганова (на фото), председатель Союза кинематографистов Республики Татарстан, режиссер Ильдар Ягафаров и драматург Мансур Гилязов.

- В программу «Караван», знакомящую публику с тюркоязычным кино, вошла наша картина «Байгал». Была у нас в Волге такая священная, мифологическая рыба. Я режиссер-постановщик и продюсер этого фильма, мы работали над ним полтора года, 2016 – 2018 годы, - рассказал читателям «Фикер» Ильдар Ягафаров. – Картина может быть выпущена на экран на трех языках, для меня очень важен показ здесь, так как я уверен, что казахи стопроцентно поймут татарскую речь. Сценарий написал известный драматург Мансур Гилязов, сын нашего великого писателя Аяза Гилязова. По жанру ленту можно определить, как философскую мелодраму. По сюжету, старик Галимзян (в исполнении Рената Галимова) давно в разводе с женой и живет один. Однажды приходит весть, что его сын (Азат Шакуров) попал в беду, в тюрьму. Старик стремится его спасти, но это сложно, в отчаянии герой обращается к священной, всемогущей рыбе байгал. И она появляется, для зрителей это очень щемящий момент… Соседа Галимзяна сыграл всенародный любимец, звезда Камаловского театра Ильдар Хайруллин, а образ следователя создал популярный российский актер Владимир Вдовиченков, Увидят зрители на экране и продюсера картины Миляушу Айтуганову.



Бюджет фильма составил около 12 миллионов рублей, съемки проходили в Казани и в деревнях. Мы очень надеемся на интерес кинопрокатчиков разных стран.

Хочется пожелать картине «Байгал» успешной фестивальной и прокатной судьбы и добавить, что казахстанская публика знакома с творчеством Ильдара Ягафарова, ведь в 2005 году в Алматы, на кинофестивале «Шакен жулдыздары» была показана его картина «Кок тау», в которой засветились лучшие представители труппы Татарского академического театра им.Галиаскара Камала, а главную роль сыграл Фарид Бикчентаев.

В программу «Караван» вошла еще одна картина из Татарстана - «Халима» режиссера Юлии Захаровой.

Также 4-5 июля в Астане прошли Дни татарстанского кино. Цикл кинопоказов стал продолжением проекта, инициированного «Татаркино» в апреле нынешнего года в Казани. В программу вошли фильмы «Байгал», «Мулла» (режиссер Р. Фазлиев), «Представь» (режиссер И. Рахимбай) и «Хлопнул дверью и ушел» (режиссер С.Юзеев).

***Зухра Табаева, Алматы. Фото автора***

***Фикер №6, 2018 ел***

**КАЗАКЪСТАН ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ БАШКОРТЛАРЫ КОНГРЕССЫ СОСТАВЫНДАГЫ ОЕШМАЛАРНЫҢ МӘДӘНИ -ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫ ФОТОГРАФИЯЛӘРДӘ**




















БІРЛІК ПЕН ЖАСАМПАЗДЫҚТЫҢ
25 ЖЫЛЫ
25 ЛЕТ
ЕДИНСТВА И СОЗИДАНИЯ









===========================================================================

*Дорогие читатели газеты!*

***Ваши материалы для помещения в газете следует отправлять в программе Word по электронной почте в адрес [griftim@mail.ru](mailto:griftim@mail.ru). Напоминаем, что редакция не рецензирует материалы, а также не выражает публично свое отношение к содержанию и форме представленных материалов.***

---


| **ГАЗЕТА "ФИКЕР" № 6 (119), 2018 год. Электронная версия.**<br>**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир** | |
|---|---|
| Главный редактор<br>**Г.Т.Хайруллин**<br>Компьютерная верстка<br>**Р.Р.Наратов** | Свидетельство о постановке на учет средств массовой информации №13715<br>от 26 июня 2013 года. Выдано Комитетом архивов Министерства культуры и информации РК |